**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры сораулары**
**2017-2018 уку елы. 8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты - 180 минут**
**максималь балл - 73**

## I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге тел арты (кече тел) ассимиляциясе чагылыш тапкан сүзләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Иллә кояшы, ерактагы зәңгәр урман эченә төшеп йоклар алдыннан, озын бер сузылып, төтен баганасын алтынга манды.* (Г.Бәширов)

а) 1;
ә) 2;
б) 3;
в) 4.

2. Тел-теш тартыкларының барысы да күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

а) [къ], [гъ], [х], [ң];
ә) [х], [ң]; [къ], [гъ], [з], [д], [ц];
б) [д], [т], [з], [с], [л], [н], [ц];
в) [м], [н], [ң].

3. Җөмләдәге ТСТ калыбына туры килә торган иҗекләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Кояш югарырак үрләде, юкәне буеннан-буена яктыртты.* (М.Рәфыйков)

а) 2;
ә) 3;
б) 4;
в) 5.

4. Архаизм булган ***мәктүп*** сүзенең хәзерге көндә кулланыла торган варианты дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

а) мәктәп;
ә) хат;
б) мәкалә;
в) укучы.

5. Яңа сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез. (2 балл)

а) куцат, айбагар, шартлама, ызба;
ә) анализ, вакланма, интервал, формула;
б) дәрес, мәдрәсә, шәкер, мулла;

в) дресс-код, лайк, супервайзер, фастфуд.

6. Җөмләдәге күчерелмә мәгънәле сүзнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Зур елгалар боз астына качтылар.* (Г.Ибраһимов)

а) образлы метафора;

ә) образлылыгын югалткан метафора;

б) индивидуаль-стилистик метафора;

в) метонимия.

7. Җөмләдәге ясалма сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Кызы мендәрләр өстендәге чигелгән япмаларны, көзгегә эленгән чиккән сөлгене алып куя.* (Т.Миңнуллин)

а) япмаларны;

ә) өстендәге, япмаларны;

б) мендәрләр, өстендәге, япмаларны;

в) мендәрләр, өстендәге, япмаларны, көзгегә.

8. ***3,7; 9,2*** кебек саннарның төркемчәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

а) микъдар;

ә) чама;

б) бүлем;

в) тәртип.

9. Җөмләдәге хәл фигыльләрнең саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Җитез сабан тургайлары, такмаклап биюче егетләр сыман, нурлы һавадан төшмичә, сайрый-сайрый, сызгыра-сызгыра җилпенәләр.* (Ә.Еники)

а) 2;

ә) 3;

б) 4;

в) 5.

10. Җөмләдәге хәбәрнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Менә табигатьтә тагын алтын көз хакимлек итә.* (Д.Гыйсметдин)

а) тезмә исем хәбәр;

ә) кушма исем хәбәр;

б) тезмә фигыль хәбәр;

в) кушма фигыль хәбәр.

11. Җөмләдәге кереш сүзнең мәгънәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Гомумән, беркем дә эшсез утырмый.* (Ф.Әһлия)

а) ышану, раслау;

ә) фикергә бәйләнгән төрле тойгы;

б) фикер тәртибе;

в) фикер нәтиҗәсе, йомгагы.

12. Җөмлә эчендәге нокталар урынына тиешле тыныш билгесе куелган рәтне билгеләгез. (2 балл)

*“Яшь техниклар” журналының безгә очкыч ... самолёт ... ясарга өйрәткән бүлеге ошады.* (Д.Гайнетдинова)

а) – – ;

ә) ( ) ;

б) , , ;

в) : – .

## II. Башыгызны эшләтегез.

Һәр җөмләдә фразеологизм файдаланып, 16 җөмләдән торган “Кышкы табигать” дигән текст уйлап языгыз. (8 балл)

## III.Теоретик бирем.

Алынма сүзләр, аларның үзенчәлекләре турында белгәннәрегезне языгыз. Фикерләрегезне мисаллар ярдәмендә аңлатыгыз. Алынма сүзләргә үз мөнәсәбәтегезне белдерергә онытмагыз. (10 балл)

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

*Үз илен яратмаган кеше берни дә яратмый.* (Мәкаль)

1. *Берни* сүзенә фонетик анализ ясагыз. (5 балл)
2. *Яратмаган* сүзенең мәгънәле кисәкләрен билгеләгез. (4 балл)
3. Барлык сүзләргә дә морфологик анализ ясагыз. (7 балл)
4. Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз, төрләрен билгеләгез, җөмләгә билгеләмә языгыз. (5 балл)
5. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз. (10 балл)